ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
АЛЕКСЕЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АЛЕКСЕЕВСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

12.03.2026 п.г.т.Алексеевское № 65

**2026 елга һәр гаилә әгъзасына яисә ялгыз яшәүче гражданга туры килә торган керемнең максималь күләмен һәм гаилә әгъзалары яисә ялгыз яшәүче граждан милкендәге һәм салым салынырга тиешле мөлкәт хакын билгеләү турында**

Россия Федерациясе Торак кодексына, «Социаль файдаланудагы торак фондының торак урыннарына наем шартнамәләре буенча гражданнарның аларга торак урыннары бирү хокукларын гамәлгә ашыру турында» 2015 елның 16 мартындагы 13-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына һәм Алексеевск муниципаль районы Башкарма комитетының 21.12.2018 ел, № 470 «Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының бердәм торак комиссиясен төзү турында» карарына, «Татарстан Республикасы бәяләүчеләр берлеге» КП ның 29.01.2026 № 13 хатына туры китереп

**карар бирәм:**

1. 2026 елга һәр гаилә әгъзасына яисә ялгыз яшәүче гражданга туры килә торган керем күләменең һәм гаилә әгъзалары яисә ялгыз яшәүче граждан милкендәге һәм салым салынырга тиешле мөлкәт хакының максималь күрсәткечләрен билгеләргә (Кушымта):

1.1. гаилә әгъзалары яисә ялгыз яшәүче граждан милкендәге һәм салым салынырга тиешле мөлкәт хакының максималь күләме:

1.1.1. ялгыз яшәүче граждан өчен – 939 915 сум;

1.1.2. ике кешедән торган гаилә өчен – 1 879 830 сум;

1.1.3. өч кешедән торган гаилә өчен – 2 819 745 сум;

1.1.4. дүрт кешедән торган гаилә өчен – 3 759 660 сум;

1.1.5. биш кешедән торган гаилә өчен – 4 699 575 сум;

1.1.6. алты кешедән торган гаилә өчен – 5 639 490 сум;

1.1.7. җиде кешедән торган гаилә өчен – 6 579 405 сум;

1.2. гаиләнең һәр әгъзасына туры килгән уртача айлык гомуми керем күләме:

1.2.1. ялгыз яшәүче граждан өчен – 35 827 сум.;

1.2.2. ике кешедән торган гаилә өчен – 35 827 сум.;

1.2.3. өч һәм аннан да күбрәк кешедән торган гаилә өчен – 35 827 руб.

2. Бердәм торак Комиссиясе әлеге карарның 1.1 һәм 1.2 пунктларына таянып, гаиләнең һәр әгъзасының яки ялгыз яшәүче гражданның керемен исәпләгәндә, аларны социаль наем шартнамәләре буенча торак урыннары бирүгә мохтаҗ дип тану максатында эш итәргә тиеш.

3. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Алексеевск муниципаль районының рәсми сайтында веб-адрес буенча: http://alekseevskiy.tatarstan.ru/ һәм Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Алексеевск муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең инфраструктура үсеше буенча урынбасары Е.Н. Мельниковка йөкләргә.

**Башкарма комитет**
**җитәкчесе** **О.Н. Леденцов**

Татарстан Республикасы
Алексеевск муниципаль районы
Башкарма комитетының
_12.02.2026_ № _65_
карарына кушымта

**2026 елга һәр гаилә әгъзасына яисә ялгыз яшәүче гражданга туры килә торган керемнең һәм гаилә әгъзалары яисә ялгыз яшәүче граждан милкендәге һәм салым салынырга тиешле мөлкәт хакының максималь күләмен билгеләүне исәпләп чыгару**

СЖ = НП х РС х РПС, монда
СЖ - базар бәясенең исәпләнгән күрсәткече яки милек бәясе чиге;
НП - бер гаилә әгъзасына торак урыны бирү нормасы;
РС - гаилә әгъзалары саны
РПС - Торак урын мәйданының бер квадрат метрының уртача исәпләнгән базар бәясе-52 217,5 сум. «Татарстан Республикасы бәяләүчеләр берлеге» КП ның 24.01.2026 ел, № 11/8 хатының уртача кыйммәте кулланылды
а) ялгыз яшәүче граждан өчен:
СЖ = 52 217,5 х 18 х 1 = 939 915,0 сум
б) ике кешедән торган гаиләгә:
СЖ = 52 217,5 х 18 х 2 = 1 879 830 сум
в) өч кешедән торган гаиләгә:
СЖ = 52 217,5 х 54 = 2 819 745 сум
г) дүрт кешедән торган гаиләгә:
СЖ = 52 217,5 х 72 = 3 759 660 сум
д) биш кешедән торган гаиләгә:
СЖ = 52 217,5 х 90 = 4 699 575 сум
е) алты кешедән торган гаиләгә:
СЖ = 52 217,5 х 108 = 5 639 490 сум
ж) җиде кешедән торган гаиләгә:
СЖ =52 217,5 х 126 = 6 579 405 сум

2. Гаилә әгъзалары яки ялгыз яшәүче граждан милкендәге һәм салым салынырга тиешле мөлкәтнең максималь бәясе СЖ ның исәп-хисап күрсәткеченә тиң дип кабул ителә.

Граждан гаиләсенең һәр әгъзасына туры килгән уртача айлык гомуми керемнең максималь күләме билгеләнә:

1) торак урыны сатып алу өчен ипотека кредиты алу мөмкинлеге булган шәһәрләрдә, гаиләнең һәр әгъзасына туры килгән уртача айлык гомуми керем дәрәҗәсеннән чыгып, агымдагы шартларда банктан ипотека кредиты алу өчен, торак урыны сатып алу өчен, СЖның исәп-хисап бәясе буенча, формула буенча билгеләнә:

ПД = 0,7 х СЖ х ПС / (1 - (1 + ПС)$^{-КП}$) / (0,25 х РС), монда:

ПД - һәр гаилә әгъзасына туры килә торган һәм СЖ исәпләү бәясе буенча торак урын сатып алу өчен агымдагы шартларда банкта ипотека кредиты алу өчен кирәкле уртача айлык җыелма керемнең максималь күләме;

СЖ- исәпләнгән күрсәткеч;

ПС - айлык кредит буенча процент ставкасы (Россия Федерациясе Үзәк банкының 27.01.2026 елга ставкасы елына 16%, ягъни аена 16/100/12 =0,013);

КП - «Татарстан Республикасы Ипотека агентлыгы» АҖ мәгълүматлары буенча кредитның бөтен срогы (айлар саны) өчен кредит буенча түләүләрнең гомуми саны кредит бирү срогы 20 ел яки 240 ай;

РС- гаилә әгъзалары саны;

0,7-кредит суммасы һәм фатир бәясе нисбәте;

0,25- кредит буенча түләү нисбәте гаиләнең айлык кереме белән;

а) ялгыз яшәүче граждан өчен:

ПД = 0,7 x 93 9915 x 0,013/ (1- $(1 + 0{,}013)^{-240}$) /(0,25 x 1) = 35824 сум

б) ике кешедән торган гаиләгә:

ПД = 0,7 x 1 879 830 x 0,013/ (1- $(1 + 0{,}013)^{-240}$) /(0,25 x 2) = 35824 сум

в) өч һәм аннан да күбрәк кешедән торган гаиләгә;

ПД = 0,7 x 2 819 745 x 0,013/ (1- $(1 + 0{,}013)^{-240}$) /(0,25 x 3) = 35824 сум